СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19.09.2018 г. Заинск № 304

**Зәй муниципаль районы милкенә караган Россия Федерациясе халыкларының дәүләт реестрына кергән начар торыштагы һәм кулланылмый торган мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) ташламалы аренда түләвен урнаштыру Тәртибен раслау һәм Зәй муниципаль районы милкенә караган Россия Федерациясе халыкларының дәүләт реестрына кергән начар торыштагы һәм кулланылмый торган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) физик һәм юридик затларга арендага бирү Тәртибе турында**

2002 елның 25 июненнән 73-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) турында”гы Федераль законның 7 нче пунктының 14.1 статьясы, Татарстан Республикасының 2005 елның 1 апреленнән 60-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасының мәдәни мирас объектлары турында”гы Законы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә Зәй муниципаль район Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Кушымталарны расларга:

Зәй муниципаль районының муниципаль милкенә караган Россия Федерациясе халыкларының дәүләт реестрына кергән начар торыштагы һәм кулланылмый торган мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) ташламалы аренда түләвен урнаштыру Тәртибен;

Зәй муниципаль районы милкенә караган Россия Федерациясе халыкларының дәүләт реестрына кергән начар торыштагы һәм кулланылмый торган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр)физик һәм юридик затларга арендага бирү Тәртибен.

2. Зәй муниципаь районы Советына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга, интернет челтәрендәге “Тарарстан Республикасының

хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басмадан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Зәй муниципаль районы Советының бюджет- финанс мәсьәләләре, икътисади үсеш һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе урынбасары** **В. Г. Акатьев**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль район Советының
2018 нче елның 10 сентябрендәге
304 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы милкенә караган Россия Федерациясе халыкларының дәүләт реестрына кергән начар торыштагы һәм кулланылмый торган мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) ташламалы аренда түләвен урнаштыру Тәртибе**

1. Әлеге тәртип Зәй муниципаль районы милкенә караган, Россия Федерациясе халыкларының дәүләт реестрына кергән начар торыштагы һәм кулланылмый торган мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) ташламалы аренда түләвен урнаштыру тәртибе кагыйдәләрен билгели (алга таба-мәдәни мирас объектлары)

2. Урнаштырылган ташламалы түләүнең шартларына керә:

2.1. Россия Федерациясе халыкларының дәүләт реестрына кергән начар торыштагы мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) Россия Федерациясе халыкларының дәүләт реестрына кергән начар торыштагы мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) кертү турындагы 2015 елның 29 июне 646 номерлы "Гомуми дәүләт реестрына кергән мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр)не Россия Федерациясенең Начар торыштагы мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр)енә кертү критерийларын раслау турында"гы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары;

2.2. 2002 елның 25 июненнән 73-ФЗ номерлы "Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) турында" Федераль законның 47.6 статьясы Россия Федерациясе законы нигезендә, мәдәни мирас объектын тапшыру 7 елдан артмаса, әзерлек вакытын һәм мәдәни мирас объектын саклау документациясе килешүен кертеп, аны арендага тапшыру 2 елдан артмаса, саклау бурычы буенча арендага алучы мәдәни мирасны саклау эшләрен үткәрергә тиеш.

3. Мәдәни мирас объектларына ташламалы арендалы түләве аренда килешүенә ия булган аукцион нәтиҗәләре буенча урнаштырыла (алга таба- аукцион)

4.Аукцион үткәргәндә мәдәни мирас объекты мәйданына аренда түләвенең башлангыч бәясе 1 кв.метры 1 сум күләмендә билгеләнә.

5. Аукцион нәтиҗәләре буенча билгеләнгән арендалы түләү күләме төзелгән килешү вакыт аралыгында артырга тиеш түгел.

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль район Советының
2018 нче елның 10 сентябрендәге
304 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы милкенә караган, Россия Федерациясе халыкларының дәүләт реестрына кергән начар торыштагы һәм кулланылмый торган мәдәни мирасы объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) физик һәм юридик затларга арендага бирү Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Зәй муниципаль районы милкенә караган, Россия Федерациясе халыкларының дәүләт реестрына кергән начар торыштагы һәм кулланылмый торган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) физик һәм юридик затларга арендага бирү Тәртибе кагыйдәләрен билгели (алга таба-мәдәни мирас объектлары).

2. Мәдәни мирас объектлары арендага, мәдәни мирас объектларын арендалауга килешү төзергә хокук бирүче аукцион уздыру нәтиҗәләреннән чыгып (алга таба – аукцион, килешү), 26.07.2006 ел 135-ФЗ номерлы "Конкуренцияне яклау"Федераль законның 17 нче статьясының 1 өлешендә каралган очраклардан тыш бирелә.

3. Аукцион Федераль монополиягә каршы хезмәтенең 10.02.2010 ел 67 номерлы " Аренда төзүгә хокук бирүче аукцион һәм конкурслар уздыру, түләүсез куллану килешүләре, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү килешүләре, муниципаль яки дәүләт мөлкәтенә карата хокукларның күчешен чагылдырган башка төрле килешүләр һәм килешү төзү сатулар уздыруны конкурс формасында уздырырга мөмкин булган мөлкәт төрләре исемлеге" нигезендә уздырыла.

4. Аукционны оештыручы булып Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты тора.

5. " Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты Мәдәният идарәсе" Муниципаль казна учреждениясе ( алга таба МКУ-"Мәдәният идарәсе") аукцион уздырылачак көннән өч айдан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы мәданият Министрлыгына мәдәни мирас объектларының начар торышын раслаучы акт ( алга таба-акт) тапшыруларын сорап мөрәҗәгать итә.

6. Аукцион Татарстан Республикасы мәданият Министрлыгыннан акт килгәч кенә уздырыла.

7. Мәдәни мирас объекты арендага 49 елга кадәр бирелә.

8. Аукцион уздыру турында мәгълүмат "Интернет " мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Россия Хөкүмәте тарфыннан билгеләнгән сатулар уздыру турында мәгълүмат урнаштыруның рәсми сайтында күрсәтелә.

9. Аукцион үткәрү турындагы мәгълүмат составына, Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы законнарында каралган башка мәгълүматтан тыш, түбәндәгеләр урнаштырыла:

а) мәдәни мирас объектының техник халәте турында мәгълүмат, 2002 елның 25 июненнән 73-ФЗ номерлы "Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирасы объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) турында" Федераль законның 47 нче

статьясында каралганча (алга таба- Федераль закон), саклау йөкләмәсе нигезендә объектны саклауны тасвирлау;

б) аренда килешүе проекты ;

в) мәдәни мирас объектын саклау буенча башкарылган төп эшләр исемлеге;

г) арендаторның мәдәни мирас объектын саклау буенча эшчәнлекне арендага бирелгән вакыттан җиде елдан да арттырмау , шул ук вакытта мәдәни мирас объектының проект документларын әзерләү һәм килештерү эшен арендага бирелгәннән соң ике елдан да арттырмау бурычлары;

д) арендаторның арендачага вазыйфаларның үтәлеше хакында бәйсез гарантия (банк гарантиясе) йөкләмәсе, мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр бәясеннән чыгып билгеләнә торган күләмдә, мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкару бурычлары (35 процентган да ким түгел) ( алга таба-бәйсез гарантия).

10. Аукционда катнашудан баш тарту өчен түбәндәге шартларның берсе нигез булып тора:

а) икенче мәдәни мирас объектына карата аренда түләве буенча бурычлары булган, шул исәптән арендаторның канәгатьләндерерлек хәлдә дә булмаган объектка карата, аренда шартнамәсе белән каралган 2 (ике) һәм аннан да күбрәк вакыт өчен, аренда түләве буенча бурычлары булу;

б) Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәлү вакыты җитеп, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр түләү буенча бурычлар булу;

в) Федераль законның 46 статьясында каралган, башка мәдәни мирас объектына арендатор яисә милекче булып торучының, шул исәптән канәгатьләндерерлек хәлдә дә булмаган хәлдәге мәдәни мирас объектына карата, сак йөкләмәсе бозылу турында, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан бирелгән документлар булу.

11. Арендатор мәдәни мирас объектын саклау буенча, саклау йөкләмәсе нигезендә күрсәтелгән мәдәни мирас объектын арендага бирелгән көннән алып җиде елдан да артмаган вакытка тулысынча башкарганнан соң, Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары нигезендә арендачы арендаланган мөлкәтне биш көн эчендә арендага алучыга язмача хәбәр иткәннән соң субарендага (поднаемга) бирү хокукы ала.

12. Арендаторның мәдәни мирас объектын саклау проект документларын әзерләү һәм килештерүне арендага бирелгәннән соң, ике ел эчендә, яки мәдәни мирас объектын саклау буенча эшчәнлекне арендага бирелгән вакыттан җиде ел эчендә эшли алмавы турында мәгълүм булган очракта, арендачы биш көн эчендә арендаторга килешүне бер яклы өзү турында белдерү кәгазе җибәрә.

Әгәр закон бозу арендатор тарафыннан мәдәни мирас объектын саклау буенча проект документларын әзерләү яки мәдәни мирас объектын саклау эшләрен үткәрү буенча эшләр башкаруда бурычын үтәмәүдә чагылса, шартнамә өзелгәндә бәйсез гарантия суммасы арендачы тарафыннан түләнергә тиеш.

13. Килешү арендатор тарафыннан бәйсез гарантия бирү буенча йөкләмә үтәлмәгән очракта, шулай ук законда һәм килешүдә каралган башка нигезләр буенча, Россия Федерациясе законнары нигезендә беряклы тәртиптә арендачы тарафыннан өзелергә тиеш.